ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $2^2$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«$2^2$. Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашкан ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның торак урыннары белән тәэмин ителү хокукы әлеге Законның 2 статьясы нигезендә исемлеккә кертелгән башка затларныкыннан өстен була.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 72-ТРЗ